Хәмидуллина, Р. Г. «Чылбырдагы безнең урын...»/ Р. Г. Хәмидуллина // Казан утлары. – 2024. - № 6. – Б. 165-171.

**Әдәби берләшмәләрдә**

## «ЧЫЛБЫРДАГЫ БЕЗНЕҢ УРЫН...»

Чаллы төбәгендә әдәби хәрәкәтне киң җәелдерү өчен күп эш башкарыла.

Яшь каләм тибрәтүчеләрне үзенә җыйнаган «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенең эшли башлавына быел көз аенда 60 ел!

Кама-Чулман буйларында зур төзелеш әле купмаган чорларда ук, 1963 елда Чаллы районының “Коммунизм байрагы” газетасы каршында әдәби берләшмәгә нигез салына. Берләшмә газетаның баш редакторы Хәнәфи Маннапов җитәкчелеге белән оештырыла. Җитәкче итеп Казан педагогия институтын тәмамлап, Биклән авылы мәктәбенә эшкә кайткан яшь шагыйрь Хәниф Хөснуллин билгеләнә. Оештыру җыелышында Татарстан Язучылар берлегеннән шагыйрь Зәки Нури катнаша.

Җитмешенче елларда, зур төзелеш башлангач, талантлы иҗат көчләре туплана, әдәби мохит көчәя, тарихка “Ләйсән” исеме белән кереп калган данлыклы әдәби-иҗат берләшмәсе төзелә.

1970 еллар азагында шәһәребезгә килеп, «Ләйсән» әдәби берләшмәсендә үзенең шәхси шигърият мәктәбен нигезләргә өлгергән күренекле татар шагыйре Кадыйр Сибгатуллин болай дип яза:

Мәңгелеккә үтеп бара торган
кешелекнең без бер буыны.
Алып кара,
өзеп ташлап кара
чылбырдагы безнең урынны!

Бу шигъри юллар безгә, кабат-кабат, үткәннәрне онытып киләчәккә барып булмавын искәртә бит. Тарихны үзгәртә алмаган кебек, берләшмә эшчәнлегенең бер генә чорын да сызып ташлап булмый.

Әдәби сәхифәләрне актара башлауга, төбәгебездә якты эз калдырган күренекле, талантлы күпме шәхеснең исеме хәтердә яңара, күңелгә якын, таныш сурәте күз алдына килеп баса: Эдуард Касыймов, Газиз Кашапов-Үзиле, Ямаш Игәнәй, Рахмай Хисмәтуллиннар... Тагын килеп, Кадыйр Сибгатуллин, Альберт Сафин, Нәҗип Мадьяров, Заһирә Гомәрова, Ирек Диндаров, Шамил Шәйдуллин... Бүгенге көндә татар укучысын матур иҗатлары белән җәлеп иткән күренекле әдипләр: Факил Сафин, Айдар Хәлим, Фәүзия Бәйрәмова, Мансур Сафин, Вахит Имамов, Рәшит Бәшәр, Данис Хәйруллин, Мирһади Разов, Амур Фәләх, Рафис Сәлимҗановлары белән горурланып яшибез. «Ләйсән»дә чыныгу алып, зур әдәби дөньяны колачлаган:

Галиәхмәт Шаһи, Нияз Вәлиев, Айрат Суфиянов, Сирень Якупова, Әлфия Ситдыйкова, Айгөл Әхмәтгалиева, Фидаил Мәҗитов һәм башка үзенчәлекле әдипләр яши шәһәрдә.

Иҗади берләшмәдә каләм чарлаган егет һәм кызларның байтагы бүген татар әдәбиятының иң мәртәбәле биеклекләренә күтәрелде. «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе, менә инде алтмыш ел дәвамында, Кама буе төбәгенең иҗат көчләрен үз тирәсенә туплап, алар өчен әдәби мәктәп ролен үтәп килә. Яшь һәм башлап язучылар иң элек «Ләйсән» шифасын тоеп көч туплыйлар, иҗат биеклекләренә үрләү өчен, шунда канат яралар.

XXI гасыр башында әдәби иҗат берләшмәсе әгъзалары һәм аларның иҗат үрнәкләре белән якыннан таныштыруны максат итеп куйган «Ләйсән тамчылары» (2007), «Ләйсән» – моңлы бишегебез» (2009), «Моң дулкынында» (2011), «Әдәби Чаллы» (2014), «Әдәби Чаллы күгендә» (2016) исемле китаплар дөнья күрде.

**Роза ХӘМИДУЛЛИНА,**
*2007 елдан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе җитәкчесе,*